**МИНИСТЕРСТВО ПРОСВЕЩЕНИЯ РОССИЙСКОЙ ФЕДЕРАЦИИ**

**Министерство образования Республики Мордовия**

**Ромодановский муниципальный район**

**МБОУ "Белозерьевская средняя общеобразовательная школа"**

| РАССМОТРЕНО | СОГЛАСОВАНО | УТВЕРЖДЕНО |
|---|---|---|
| Методобъединение | Зам.директора по УВР | Директор школы |
| ______________________ | ______________________ | ______________________ |
| Савинова М.Н. | Манеева Л.Р. | Киреева Э.И. |
| Протокол №1 от «31» августа2023 г. | Протокол №1 от «31» августа2023 г. | Приказ № 93 от «31» августа2023 г. |

Рабочая программа

учебного курса «Родная (татарская) литература» в 6 классе ФГОС

Составитель:
Курмаева Х. А.
учитель родного языка
и литературы
МБОУ «Белозерьевская СОШ»

с. Белозерье, 2023 год

## Аңлатма язуы

Эш программасы «Рус телендә гомуми төп һәм урта белем бирү мәктәпләренең татар сыйныфлары (V–IX сыйныфлар) өчен татар әдәбиятыннан үрнәк программа» (Ф.Х. Җәүһәрова, К.С. Фәтхуллова. Казан, 2013) һәм «Рус телендә гомуми төп һәм урта белем бирү оешмаларының татар сыйныфлары өчен татар әдәбиятыннан программа» (Төзүче-авторлар: Ф.Ф. Хәсәнова, Г.М. Сафиуллина, М.Я. Гарифуллина), 6 нчы сыйныф өчен Ф.Ф. Хәсәнова, Г.М. Сафиуллина, М.Я. Гарифуллиналар эшләгән (Казан, Мәгариф – Вакыт, 2014), Татарстанның Мәгариф һәм Фән министрлыгы тарафыннан тәкъдим ителгән дәреслеккә нигезләнеп төзелде. Укыту планында каралганча, татар әдәбияты дәресләре өчен эш программасы атнага 1 сәгать исәбеннән елга 34 сәгатькә төзелде.

### Рус мәктәпләрендә укучы татар балаларына әдәбият укытуның төп максаты һәм бурычлары

1. Укучының татар әдәби телен үзләштерүенә, текстны аңлап, сәнгатьле итеп, йөгерек укуына, дөрес яза белүенә, әдәби тел формаларын саклап, төрле темаларга иркен сөйләшүенә ирешү, матур әдәбият әсәрләрен мөстәкыйль уку күнекмәләре формалаштыру, телдән һәм язма сөйләмнәрен үстерү.
2. Балаларны гомумән татар әдәбияты, халык авыз иҗаты, татар халкының җыр-музыкасы, сынлы сәнгате белән таныштыру, күренекле язучылар һәм ал арның әсәрләрен үзләштерүләренә ирешү, матур әдәбият әсәрләрен (яки әдәби әсәрләрдән өзекне) укып үзләштерү, алар турында үз фикерләрен әйтергә өйрәтү.
3. Әдәби-теоретик төшенчәләрне аңлату һәм кулланырга өйрәтү.
4. Укучыларга татар халкының килеп чыгышы, тарихи язмышы, милләттәшләребез тормышы турында мәгълүмат бирү.
5. Халык тарихын һәм мирасын өйрәнү аша укучыларда Ватанга, халыкка, туган телгә мәхәббәт, олыларга, кечеләргә һәм гомумән кешегә ихтирам, мәрхәмәтлелек, шәфкатьлелек тәрбияләү. Эстетик тәрбия бирү, табигатькә сакчыл, мәрхәмәтле караш булдыру.
6. Татар, рус һәм башка халыклар әдәбиятларын чагыштырып карау күнекмәләрен үстерү.
7. Әдәби әсәрләрне өйрәнү барышында укучыларны сәнгатьле уку алымнарына өйрәтү дә әһәмиятле. Бу җәһәттән эш түбәндәге юнәлешләрдә алып барыла:

– татар теленең үзенчәлекле авазларын әйтү күнекмәләре булдыру;
– сүз басымын дөрес куя белү;
– логик басымны дөрес куя белү;
– җөмләне фразаларга бүлү һәм дөрес пауза белән уку;
– тавышны дөрес төшерә һәм күтәрә белү, ягъни интонацияне дөрес куллану күнекмәләре булдыру һ. б.

Программада ятлау өчен әсәрләр тәкъдим ителә, укучыларның уку сыйфатын билгеләү максатында, әдәби әсәрләр белән эшләүгә, әдәбият теориясеннән белем-күнекмәләр булдыруга таләпләр бирелә. Матур әдәбиятны төрле яклап өйрәнү һәм үзләштерү укучыларның сөйләм һәм язу күнекмәләрен камилләштерергә ярдәм итә. Шуңа күрә урта белемгә ия булган яшьләр ана телендә ачык фикерле, иркен сөйләшә, дөрес яза белергә тиеш.

**Укытуның көтелгән нәтиҗәләре**

– сүз сәнгатенең образлы табигатен тою;
– өйрәнгән әдәби әсәрнең эчтәлеген аңлау;
– классик әдипләрнең (Х. Такташ, Ш. Маннур, М. Гафури, Ә. Еники, М. Мәһдиев) биографик белешмәләре;
– өйрәнгән әдәби-теоретик төшенчәләрне истә калдыру;
– әдәби текстны кабул итү һәм анализлау;
– әдәби текстның мәгънәви өлешләрен аерып чыгару, укылган буенча тезислар һәм план төзү;
– әдәби әсәрнең төрен һәм жанрын ачыклау;
– укыган әсәрнең темасын, проблемасын билгеләү;
– геройларга характеристика бирү;
– сюжет, композиция үзенчәлекләрен, махсус сурәтләү чараларының ролен ачу;
– әдәби әсәрдәге эпизодларны һәм геройларны чагыштыру;
– укылганга үзеңнең мөнәсәбәтеңне белдерү;
– әсәрне (өзекне) сәнгатьле итеп уку;
– кабатлап сөйләүнең төрләреннән файдалану;
– өйрәнелгән әсәргә бәйле рәвештә, телдән һәм язмача фикер белдерү;
– укылган әсәр буенча фикер алышуда катнашу, фикерне дәлилле белү;
– татар әдәби теленең нормаларына нигезләнеп, кирәкле темага телдән һәм язмача бәйләнешле текст төзү;
– эстетик зәвыкка туры килә торган әдәби әсәрләрне сайлау һәм аларны бәяләү;
– аерым автор, аның әсәре, гомумән әдәбият турында кирәкле мәгълүматны белешмә әдәбият, вакытлы матбугат, Интернет чаралары һ.б. аша эзләү.

## Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр

– шәхеснең әхлакый-рухи сыйфатларын камилләштерү, күпмилләтле илебезгә карата ярату хисләре, татар әдәбиятына һәм башка халыклар әдәбиятына, мәдәниятенә ихтирамлы мөнәсәбәт тәрбияләү;

– төрле мәгълүмат чараларын танып-белү һәм аралашу мәсьәләсен хәл иткәндә (сүзлекләр, энциклопедия, Интернет ресурслар һ.б.) куллану;

– активлыкка, мөстәкыйль фикер йөртүгә, акыл эшчәнлегенә һәм рухи эшчәнлеккә өйрәтү, шәхес буларак формалашуны дәвам итү;

– үзең белән идарә итүгә юнәлдерелгән белем һәм күнекмәләрне тормышның төрле шартларында куллана белергә өйрәнү, тормышта үз урыныңны күзаллый башлау;

– милли горурлык, гражданлык хисләре формалаштыру;

– әхлак нормаларын, җәмгыятьтә яшәү кагыйдәләрен үзләштерү.

## Метапредмет нәтиҗәләре

– проблеманы аңлый белү, гипотеза чыгару, материалны төзү, үз фикереңне раслау өчен дәлилләр сайлый белү, телдән (диалогик, монологик) һәм язма сөйләмдә сәбәп-нәтиҗә бәйләнешен аерып алу, нәтиҗәләрне формалаштыру;

– укучының үз эшчәнлеген мөстәкыйль рәвештә оештыра белүе, бәяләү, үзенең кызыксынучанлык өлкәсен билгеләве;

– төрле мәгълүмат чаралары белән эшли, кирәкле мәгълүматны таба, анализлый һәм үз эшчәнлегендә куллана белүе;

– әдәбиятны музыка, рәсем сәнгате белән бәйләп, сүз сәнгатенең кыйммәтен күрсәтү, матурлыкны таныргa өйрәтү;

– әдәбиятны тел белеме белән бәйләп, әдәби әсәр теленең үзенчәлекләрен, әсәр стилен җиткерү;

– татар әдәбиятын рус әдәбияты, башка халыклар әдәбиятлары белән бәйләп укытып, әдәбиятлар арасындагы уртак проблемаларны, уртак кыйммәтләрне күрсәтү аша, дөнья культурасы белән таныштыру;

– әдәбиятны тарих, җәмгыять белеме, экология предметлары белән бәйләп, дөнья, яшәү, табигать, кешелек җәмгыяте турында күзаллау формалаштыру.

**Коммуникатив УУГ (КУУГ):**

– төрле фикерләрне исәпкә алып эш итү;

– үз фикерен текстган өземтәләр китереп дәлилли белү;

– бер фикер кабул иткәнче, төрле җавапларны тыңлау, чагыштыру, нәтиҗә ясау;

– күмәк эш вакытында, бигрәк тә фикер агышлары төрле булганда, бер фикергә килә белү;

– укылган, тыңланган әсәрләр буенча сораулар бирә алу;
– үз эшен контрольдә тоту, иптәшләренә ярдәм итү;
– коммуникатив күнекмәләрнең кеше тормышындагы ролен билгеләү;
– үз фикерләрен телдән һәм язма формада җиткерә белү;
– башкаларны тыңлый, кирәк булганда үз фикерләрен үзгәртә алу;
– иптәшләре каршында төрле темаларга чыгыш ясау;
– бергәләп эшләгәндә бердәм карар кабул итә белү;
– текст буенча сораулар куя белү.

**Предмет нәтиҗәләре**

**Танып-белү өлкәсендә:**
– төрле жанрдагы әдәби әсәрләрне аңлап һәм иҗади уку;
– сәнгатьле уку;
– шигъри кабатлап сөйләүнең төрле төрләреннән файдалану (тулы итеп, кыскача, сайлап, аңлатмалар белән, иҗади бирем белән);
– текстларны яисә чәчмә әсәрдән өзекләрне яттан өйрәнү;
– әсәрләрне анализлау һәм шәрехләү;
– план тезү;
– әдәби әсәрләр буенча һәм тормыштан алган фикер-карашларга, хис-кичерешләргә нигезләнеп, тулы яки мини сочинение язу;
– укучыларны иҗади эшчәнлеккә тарту, проект эшләре белән кызыксындыру;
– татар һәм башка халыклар фольклорында, Россия һәм чит ил классиклары иҗатында төп проблемаларны аңлау;
– әдәби әсәрләрнең чор һәм язылышы арасындагы бәйләнешен, аларда салынган вакыт, шәхси кыйммәтләр, аларның яңача яңгырашын аңлау;
– әдәби әсәрләрне анализлау, аларның билгеле бер жанрга каравын, теманы аңлау һәм формалаштыру, идеясен тотып ала белү;
– әдәби әсәрнең әхлакый ягын дөрес чамалау;
– геройларга характеристика бирү, төрле әсәрдәге бер яки берничә герой белән чагыштыра белү;
– композиция, сюжет элементларын, телнең сурәтләү чараларын, аларның әсәр эчтәлеген ачкандагы ролен ачыклау;
– әдәби әсәрне анализлаганда гади әдәби терминология куллану;
– өстәмә белем чыганакларыннан язучыларның тормышы һәм иҗаты турында мәгълүмат алу;
– татар әдәбиятының һәм сәнгатенең күренекле вәкилләре, аларның иҗаты турында белү;

– әдәби әсәрне, язучы иҗатын мөмкин кадәр мөстәкыйль анализлау, чор белән бәйләү өчен кирәкле булган тарихи, сәяси һ.б. мәгълүматлар бирү.

**Әхлакый кыйммәтләр юнәлеше өлкәсендә:**

– татар әдәбияты һәм мәдәниятенең әхлакый һәм рухи кыйммәтләрен үзара якынайту, башка халыкларныкы белән чагыштыру;

– татар әдәбиятына үз мөнәсәбәтен формалаштыра, бәяли белү;

– өйрәнелгән әдәби әсәрләргә аерым очракларда үзгәреш кертә алу;

– автор карашын, мөнәсәбәтен аңлау.

**Коммуникатив өлкәдә:**

– төрле жанрдагы әдәби әсәрләрне ишетеп кабул итү, аңлаешлы уку, эчтәлекне дөрес аңлау;

– чәчмә әсәрләрне яки өзекләрне татар теленең әдәби чараларын һәм цитаталарын кулланып сөйли белү, укыган яки ишеткән текст буенча сорауларга җавап бирү, телдән төрле типтагы монолог, диалоглар төзү, әңгәмә кору;

– бирелгән темага, укылган әсәр темасы, проблемасына сочинение, сыйныф яки өйгә бирелгән иҗади эшләр, гомуммәдәният темаларына проект эшләре башкару.

**Эстетик өлкәдә:**

– әдәбиятның образлы дөньясын сүз сәнгате күренеше буларак аңлау, әдәби әсәрләрнең эстетик ягын кабул итү, әсәрләрдән рухи тәм табу;

– сүзнең эстетик вазифасын, әдәби образлар тудырганда сурәтләү көчен аңлау.

## МЕТОДИК АҢЛАТМАЛАР

1. Әдәби сүзлек дәреслек ахырында бирелә.
2. Дәреслектәге шартлы билгеләр укытучыга укучылар белән эшне дөрес планлаштырырга, ә укучыларга мөстәкыйль рәвештә дәреслектә ориентлашырга мөмкинлек бирә.
3. Балаларны әсәрләрнең авторлары белән таныштыру максатыннан, әдипләрнең портретлары һәм ал арның тормышы турында кыскача фактик материаллар, алар турында башка язучы һәм галимнәр фикерләре бирелде.
4. Татар әдәбияты белән кызыксынуларын үстерү өчен, кызыклы мәгълүматлар тупланды.

5. Рәссамнарның картиналары белән танышкан вакытта, укучыларның сөйләм телләрен, күзәтүчәнлекләрен, матурлыкка соклана белү хисләрен, гади генә предметны да образлы итеп күрә белүләрен үстерергә, музейлар, картиналарның язылу тарихы, эшләнеш алымы турында кыскача мәгълүмат бирергә кирәк.

6. Балаларны татар язучылары музейлары белән таныштыру максатыннан, әдәби музейлардан фоторепортаж бирелде, адреслары күрсәтелде.

7. Дәрес өчен материал күп. Көчле укучылар белән эш оештыру өчен, укытучының барлык мөмкинлекләре дә бар. Дәреслекнең 2 нче кисәгендә дә җитәрлек әсәрләр сайланды. Укытучыга башка чыганаклардан өстәмә әсәрләр эзләмәскә дә була. Күрсәтелгән барлык материалларны эшләп бетерү мәҗбүри түгел, сыйныфның әзерлек дәрәҗәсенә карап, укытучы үзе сайлап ала. Дәрестә бирелгән материал күп дип уйлаганда, биремнәрне төрле әзерлектәге укучыларга, сайлап, мөстәкыйль эш итеп бирсәң дә була.

8. Сәнгать әсәрләренең берсе булган музыка белән танышу, тыңлау аны әдәби һәм сынлы сәнгать әсәрләре белән чагыштырырга мөмкинлек бирә, образлы фикерләү сәләтләрен үстерә.

9. Сәнгатьле укырга өйрәткәндә дәреслек кушымтасы булган CD дискларны файдалану күздә тотыла, электрон дәреслек тә әзерләнә.

10. Дәресләр ахырында укытучы өчен өстәмә материал бирелде. Һәр дәрескә язылган технологик карталарның мотивация өлешендә, татар теле турында шагыйрьләр шигырьләрен укы тучы үзе укый. Бу – туган тел белән кызыксыну уятуны күздә тотып эшләнде.

11. Өй эшләре, сайлап алу өчен, берничә вариантта бирелде.

## 6 НЧЫ СЫЙНЫФТА ПРОГРАММА МАТЕРИАЛЫНЫҢ СӘГАТЬЛӘРГӘ ЯКЫНЧА БҮЛЕНЕШЕ

| № | Тема/ эчтәлек | Кайсы китап, ничәнче битләр? | Үтәлү вакыты | |
|---|---|---|---|---|
| | | | план | факт |
| 1 | **Халык авыз иҗаты (1 с)** | | | |
| | Халык җырлары. Фәнис Яруллин. «Җыр». Җыр турында галимнәр фикере. Иҗади эш.. | 1 нче кисәк, 5–13 нче битләр<br>2 нче кисәк, 6-9 нчы битләр | | |
| 2 | **Борынгы әдәбият үрнәкләре (1 с)** | | | |
| | Йосыф Баласагунлы һәм «Котадгу белек» поэмасы турында. «Котадгу белек» (поэмадан өзек). «Тел турында». | 1нче кисәк, 14–15 нче битләр<br>2 нче кисәк, 9–10 нчы битләр | | |
| 3 | **XVIII йөз әдәбияты (1 с)** | | | |
| | Габдерәхим Утыз Имәни турында.<br>Габдерәхим Утыз Имәни. «Гыйлемнең өстенлеге турында». «Сату итү турында», «Татулык турында». Проект эше. Мөхәммәдшәриф Габдрәшит улы. «Кәҗә бәете». Бәет турында төшенчә. | 1 нче кисәк, 16–18 нче битләр<br>2 нче кисәк, 10–11 нче битләр | | |
| 4 | **XIX йөз әдәбияты (1 с)** | | | |
| | XIX йөз әдәбияты. Габделҗаббар Кандалый турында. Габделҗаббар Кандалый. «Мулла белән абыстай». Юмор һәм сатира. «Кыйссаи Ибраһим Әдһәм». | 1 нче кисәк, 19–23 нче битләр<br>2 нче кисәк, 11–12 нче битләр | | |
| | **XX йөз әдәбияты (8 с)** | | | |
| 5 | Габдулла Тукай. «Туган авыл». Арчадагы Әлифба музее.<br>. «Шүрәле». Поэма жанры. «Шүрәле» балеты турында | 1 нче кисәк, 24 нче бит, 146–148 нче битләр.<br>1 нче кисәк, 25–33 нче битләр | | |
| 6 | Габдулла Тукай. «Исемдә калганнар». | 2 нче кисәк, 24–30 нчы битләр | | |
| 7 | Сыйныфтан тыш уку (СТУ). Гаяз Исхакый турында. Гаяз Исхакый. «Кәҗүл читек». Тест эшләү | 1 нче кисәк, 33–40 нчы битләр | | |
| 8 | Мәҗит Гафури турында. Уфада Мәҗит Гафуриның мемориаль музей-йорты. «Ана». «Ана теле». Тест эшләү | 1 нче кисәк, 40-45 нче бит, 142–144 нче битләр | | |
| 9 | БСҮ. Мәҗит Гафури. «Урман». Разил Вәлиев. «Урман». И. Шишкин. «Кояшлы көндә нарат урманы». | 2 нче кисәк, 31–33 нче битләр | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 10 | һади Такташ турында. Һади Такташ. «Иптәшләр». һади Такташ. «Мокамай». Лирик герой Һади Такташ. «Ак чәчәкләр» | 1 нче кисәк, 45–46 нчы битләр, 52–53 нче битләр<br>1 нче кисәк, 47–52 нче битләр<br>1 нче кисәк, 54–55 нче битләр | | |
| 11-12 | Ибраһим Гази турында. Ибраһим Гази. «Онытылмас еллар» (өзек). Лена Шагыйрьҗан. «Рәхмәт игенчегә!» | 1 нче кисәк, 56–65 нче битләр<br>2 нче кисәк, 34–42 нче битләр | | |
| **Бөек Ватан сугышы чоры әдәбияты (4с)** | | | | |
| 13 | Муса Җәлил. «Вәхшәт», «Имән», «Чәчәкләр». | 2 нче кисәк, 43–45 нче битләр<br>1 нче кисәк, 66–71 нче битләр | | |
| 14 | Нәби Дәүли. «Дошманнан үч алыгыз».<br>Әхмәт Исхак. «Һөҗүмгә барганда». | 1 нче кисәк, 70–71 нче битләр<br>2 нче кисәк, 49–50 нче битләр | | |
| 15 | БСҮ. Хәйретдин Мөҗәй турында. Хәйретдин Мөҗәй. «Бүләк». Иҗади эш. | 2 нче кисәк, 45–49 нчы битләр | | |
| 16 | Шәйхи Маннур турында. Шәйхи Маннур. «Саубуллашу җыры», «Чәчәкләр һәм снарядлар».СТУ. Шәйхи Маннур. «Татар кызы». | 1 нче кисәк, 71–73 нче битләр<br>2 нче кисәк, 50–52 нче битләр | | |
| 17-18 | **Тыныч ил сагында (11 с)** | | | |
| | Тыныч ил сагында. Мөхәммәт Мәһдиев турында. Мөхәммәт Мәһдиев. «Фронтовиклар» (озек). Иҗади эш. Сочинение. | 1 нче кисәк, 74–84 нче битләр | | |
| 19 | Кави Латыйп. «Җиңү парады».<br>Иҗади эш. Разил Вәлиев. «Мәхәббәт һәм нәфрәт». | 2 нче кисәк, 53–54 нче битләр | | |
| 20 | БСҮ. Шәүкәт Галиев турында. Шәүкәт Галиев. Аталы-уллы солдатлар» (баллада). Баллада жанры.<br>«Азатлык алып килгән сугышчы» монументы. | 1 нче кисәк, 85–88 нче битләр | | |
| 21-22 | Шамил Маннапов турында. Шамил Маннапов. «Тыңланмаган моңнар», . «Солдатта булган, диләр...»Рөстәм Акъегет. «Мәңгелек ут яна мәйданнарда». Җәүдәт Дәрзаман. «Батырлык». Эльмира Шәрифуллина. «Туган җир». Фәнис Яруллин. «Туган ягы кирәк кешегә». | 1 нче кисәк, 88–90 нчы битләр<br>2 нче кисәк, 56–58 нче битләр<br>2 нче кисәк, 58–60 нчы битләр | | |
| 23-24 | Әмирхан Еники турында. **Әмирхан Еники.«Матурлык». Хикәя жанры.Сочинение СТУ. Мөхәммәт Мирза. «Балачак хатирәсе». | 2 нче кисәк, 60–62 нче битләр<br>1нче кисэк 91-102 битлэр | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 25-26 | Гомәр Бәширов турында. «Язгы сабан туйлары» «Сабан туе».<br>БСҮ. «Сабантуй». Картиналар буенча эш. «Кунак кызлар килде утырмага.» | 2 нче кисәк, 77–79 нчы битләр<br>1 нче кисәк, 103–115 нче битләр 2 нче кисәк, 62–77 нче битләр | | |
| 27 | Дания Гайнетдинова. «Ташлыяр Карлыгачы». | 2 нче кисәк, 79–89 нчы битләр | | |
| **Тәрҗемә әсәрләр (2 с)** | | | | |
| 28 | Тәрҗемә әсәрләр. **Антон Чехов. «Анюта». Антон Чехов турында. | 1 нче кисәк, 116–120 нче битләр | | |
| 29 | СТУ. Һанс Кристиан Андерсен. «Борчак өстендәге принцесса». Константин Паустовский. «Корыч балдак». | 2 нче кисәк, 89–91 нче битләр<br>2 нче кисәк, 91–98 нче битлар | | |
| **Язучылар елмая (2 с)** | | | | |
| 30 | Язучылар елмая. Радик Фәизов. «Батыр әйтте».<br>Гамил Афзал. «Мыек борам».Газиз Мөхәммәтшин. «Каз боткасы». Проект эше. «Балыкчы». Эстон халык җыры. | 1 нче кисәк, 121–123 нче битләр<br>2 нче кисәк, 101–102 нче битләр<br>1 нче кисәк, 123–131 нче битләр | | |
| 31 | Ибраһим Гази. «Мәүлия нигә көлде?»<br>Гәрәй Рәхим. «А-ля-шәр туны». | 1 нче кисәк, 98–101 нче битләр<br>1 нче кисәк, 140–142 нче битләр | | |
| | **Татар телем – энҗе-мәрҗән тулы тел (3 с)** | | | |
| 32 | Хәсән Туфан турында. Хәсән Туфан. «И минем җандай кадерлем...» Хәсән Туфан музее. БСҮ. Хәсән Туфан. «Туган тел». Искәндәр Рәфыйков. «Әй туган тел!» Картина белән эшләү.Сочинение. | 1 нче кисәк, 132–135 нче битләр,<br>144–145 нче битләр | | |
| 33 | Нажар Нәҗми. «Татар теле».<br>Шәүкәт Галиев. «Туган телем». Ренат Харис. «Туган җирем». | 2 нче кисәк, 103–105 нче битләр<br>2 нче кисәк, 105 нче бит | | |
| 34 | Равил Фәйзуллин турында. Равил Фәйзуллин. «Минем телем». Роберт Миңнуллин турында. Роберт Миңнуллин. «Туган телемә». Н. Акмал. «Кешеләргә карап». | 1 нче кисәк, 136–137 нче битләр<br>2 нче кисәк, 106 нчы бит<br>1нче кисәк, 138–139 нчы битләр<br>2 нче кисәк, 106–107 нче битләр | | |